Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

02.12.2020 Менделеевск ш. № 686

2020-2021 елның кышкы чорында
Менделеевск муниципаль районы
территориясендә автомобиль һәм тимер юл
транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "2020/2021 елның кышкы чорында Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль һәм тимер юл транспортының өзлексез хәрәкәтен тәэмин итү турында" 2020 елның 22 августындагы 721 номерлы карарын үтәү йөзеннән Менделеевск муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитет җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасарына, авыл җирлекләре башлыкларына тәкъдим итәргә:

2020 елның 1 декабренә кадәр җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту буенча муниципаль контрактлар төзүне оештырырга; 2020 елның 25 декабренә кадәр - 2021 елның 1-2 кварталына җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту буенча муниципаль контрактлар төзергә;

юл-коммуналь хезмәтләрне кышкы шартларда эшләргә әзерләүне оештырырга һәм шәһәр һәм авыл җирлекләренең тормыш-көнкүрешен тиешле дәрәҗәдә тәэмин итү өчен кирәкле урам-юл челтәрен карап тотуны тәэмин итәргә;

юл-коммуналь хезмәтләрендә куркыныч метеорологик күренешләр барлыкка килгәндә үз техник чаралары җитмәгән очракта, өстәмә техника бүлеп бирүгә чит оешмалар белән шартнамәләр төзүне оештырырга.

2. «Татарстан Республикасы буенча федераль янгынга каршы хезмәтнең 15 отряды» федераль дәүләт казна учреждениесенең 86 янгын сүндерү-коткару бүлеге башлыгына 2020 елның 1 декабренә кадәр Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы территориясендә автомобиль юллары һәм тимер юллары буенча хәрәкәтне туктату белән бәйле гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча «Буран» оператив планын тәкъдим итәргә (А.Ю. Балясов).

3. «Менделеевск үзәк район хастаханәсе» ДАССО баш табибына (Бахматова О.А.) 2020 елның 1 декабреннән кадәр сәламәтлек саклау оешмаларының кар көртләре, автомобиль катастрофалары нәтиҗәсендә изоляцияләнгән затларга үз вакытында медицина ярдәме күрсәтү гамәлләренә әзерлеген тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

4. Шәхси эшмәкәр Л..И. Салиховага кар көртләрендә изоляцияләнгән затларны чыгару өчен җәмәгать транспортын тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

5. Башкарма комитет җитәкчесенең шәһәр хуҗалыгы буенча урынбасары (С. В. Метальников) 2020 елның 1 нче декабренә кадәр Менделеевск муниципаль районы

юлларында 2020-2021 елларның кышкы чорында куркыныч метеорологик күренешләр барлыкка килгәндә кайнар аш һәм азык-төлек белән тәэмин итү бурычы йөкләнә торган предприятиеләр исемлеген билгеләргә һәм тапшырырга, шулай ук район территориясендә «Буран» планын керткәндә аларның эшләрен координацияләүне гамәлгә ашырырга.

6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Менделеевск районы буенча ЮХИДИ бүлеге башлыгына кар көртләре барлыкка килгән урыннарга юл һәм махсус техника хәрәкәтендә автомобиль юлларын карап тотуны гамәлгә ашыручы оешмаларга, шулай ук зур төркем кешеләрне, шул исәптән балаларны йөртүче автомобиль колонналарын һәм җәмәгать тукланууы һәм сәүдәнең махсуслаштырылган күчмә формированияләрен транспортның вакытлыча туплану урыннарына илтүне оештыруда ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

7. Куйбышев тимер юлының Круглое Поле дистанциясе башлыгына, «Л. Я. Карпов исемендәге Химзавод» АҖ генераль директорына, «Аммоний» АҖ генераль директорына Менделеевск муниципаль районы территориясе аша узучы тимер юлларда кар көртләрен бетерү өчен эшчеләр һәм техника бүлеп бирү турында килешүләр төзергә тәкъдим итәргә.

8. «Ижминводы» шифаханәсе директорына, «Метелица» ҖЧҖ директорына, «Дилижанс» кунакханә комплексы хуҗасына кар көртләре, автомобиль катастрофалары урыннарыннан чыгарылган затларны вакытлыча урнаштыру өчен урыннар булдыруны тәкъдим итәргә.

9. Менделеевск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы Рәисенә (Григорьев М. В.) 2020-2021 елның кышкы чорында мөмкин булган гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен финанс чараларын карарга тәкъдим итәргә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш, торак-коммуналь хуҗалык һәм стратегик үсеш буенча беренче урынбасары вазифаларын башкаручы Захарян А.А. йөклим.

Җитәкче Р.А. Абдуллин

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:

Юридик бүлек башлыгы Е.С. Царёва